# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге составына керүче Югары Козгынчы торак пунктында 2024 елга үзара салым кертү турында

№ 1 19 октябрь 2023 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчыстатьялары, «Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Югары Козгынчы торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Югары Козгынчы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары(хатыны һәм 18 яшькәчә балалары) күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белеем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2024 елда 500(биш йөз ) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Югары Козгынчы торак пунктында Трактористлар урамындагы юлларны ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Югары Козгынчы торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;
- Югары Козгынчы торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (махсус җиһазлар, лампалар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3.Әлеге карарны Олыяз авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Олыяз авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе И.Я.Хаев